ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.11.2025 г.Лениногорск № 978

Татарстан Республикасының «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2018 елның 14 мартындагы 254 номерлы карары белән расланган Лениногорск муниципаль районында Яшьләр белән системалы эшләү буенча иҗтимагый координация советы эше турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җәмәгать контроле нигезләре турында» 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасының «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2018 елның 14 мартындагы 254 номерлы карары белән расланган Лениногорск муниципаль районында Яшьләр белән системалы эшләү буенча иҗтимагый координация советы эше турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.6 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар»;

2 пунктның 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«яшьләр проблемаларын хәл итүгә, яшьләрнең социаль инициативаларын, шулай ук Лениногорск муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш программасын гамәлгә ашыруга кагылышлы Татарстан Республикасы һәм

Лениногорск муниципаль районының максатчан программаларын гамәлгә ашыруда яшьләрнең катнашуы өчен шартлар тудыру».

2.Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына Нигезләмәнең 4.6 пункты нигезендә комиссия составын туры китерергә һәм 2025 елның 20 ноябренә кадәр раслауга тапшырырга.

3.Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче А.Г. Шәмәрданов

М.Галимова
5-17-41